СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

31.10.2025 № 2/14

На № ___________ от _______________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 27/6 номерлы карары белән расланган Хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, район уставы, 2025 елның 22 сентябрендәге 02-08-02-2025/531-25-20920036 номерлы прокуратура протесты нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 20 августындагы 27/6 номерлы карары белән расланган Хезмәт (вазифа) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3 пунктының «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) муниципаль хезмәткәрләрнең, коррупциягә каршы тору максатында, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы Федераль законда, башка федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турында таләпләрне, бурычларны үтәвен тәэмин итүдә (алга таба – хезмәт тәртибенә таләпләр һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләр);»;

1.2. 3.1 пунктына түбәндәге эчтәлектәге «е» пунктчасын өстәргә:

«е) хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәүгә комачаулый торган, аңа бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу турында муниципаль хезмәткәр хәбәрнамәсе;

1.3. 3.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.2) әлеге Нигезләмәнең «б» пунктчасы 4 абзацында һәм 3.1 пункты «е» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр дәүләт органы кадрлар хезмәтенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча бүлекчәсе

тарафыннан карала, ул хәбәрнамәләрне карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән бәяләмәләр әзерли;»;

1.4. 3.4 пунктта «әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пункты «б» һәм е» пунктчалары белән» сүзләренә алыштырырга;

1.5. 3.4.1 пунктында «3.1 пункты «б» пунктчасы белән» сүзләрен «3.1 пункты «б» һәм е» пунктчалары белән» сүзләренә алыштырырга;

1.6. Нигезләмәнең 3 өлешенә түбәндәге эчтәлектәге 3.10.4 пунктын өстәргә:

«3.10.4. Әлеге Нигезләмәнең 16 пункты «е» пунктчасында күрсәтелгән мәсьәләне карау нәтиҗәлләре буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булуын танырга;

б) муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган хәлләр килеп чыгу һәм аның хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турында таләпләрне үтәү мөмкин түгеллеге арасында сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булмавын танырга.»;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен котрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазифаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары Р.И. Закиров